ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 526-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ю.З. Камалтынов, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 526-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2338-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:
«13) әлеге Законның $17^3$ статьясында каралган анкетада булган белешмәләрдәге аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында, яллаучы вәкиле карары белән үзгәргән белешмәләрдән тыш (алга таба – анкетадагы белешмәләр), яллаучы вәкиленә язмача хәбәр итәргә.»;

2) 17 статьяның 3 өлешендә «дәүләт хезмәткәре тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $17^3$ статья өстәргә:

«$17^3$ статья. **Анкета тапшыру, анкетада булган белешмәләрнең үзгәрүе турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү**

1. Граждан дәүләт хезмәтенә урнашканда Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнгән рәвештәге анкета тапшыра.

2. Дәүләт хезмәткәре яллаучы вәкиленә анкетада булган белешмәләрдәге аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында язмача хәбәр итә.

3. Анкетадагы белешмәләр яллаучы вәкиленең яисә ул вәкаләт биргән затның карары белән тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне тикшерү дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүмат булган гавами хакимият органнарына һәм оешмаларга язмача соратулар, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, әлеге Законның $41^1$ статьясында каралганнарын да кертеп, җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Тиешле мәгълүмат булган гавами хакимият органнары һәм оешмалар соратыла торган мәгълүматны әлеге соратуны алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

4) 31 статьяның 1 өлешендәге $6^1$ пунктында «Кораллы Көчләренә» сүзләреннән соң «яисә Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренә» сүзләрен өстәргә;

5) 32 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 һәм 13 пунктлар өстәргә:

«12) 2014 елның 11 маеннан 2022 елның 23 февраленә кадәр Россия Федерациясе гражданлыгы алган һәм шушы чорда, даими яшәү срогына бәйсез рәвештә, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территориясендә даими яшәгән Россия Федерациясе гражданнары һәм элек Украина гражданлыгында булган һәм 2022 елның 24 февраленнән башлап Россия Федерациясе гражданлыгы алган Россия Федерациясе гражданнары 1992 елның 1 гыйнварыннан 1993 елның 31 декабренә кадәр Украина ССР Конституциясе, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә гамәлдә булган норматив хокукый актлар нигезендә төзелгән дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында биләгән җитәкчеләр, белгечләр вазыйфаларын, шулай ук даими (штат) нигездә биләгән сайлаулы вазыйфаларны;

13) әлеге өлешнең 12 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнары Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә Украина законнары нигезендә 1994 елның 1 гыйнварыннан алып дәүләт вазыйфаларын яисә муниципаль вазыйфаларны биләү, Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә яисә Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә урнашу көненә кадәр биләгән вазыйфаларны (Россия Федерациясе законнары нигезендә террорчы булып танылган хәрби формированиеләрдә һәм башка формированиеләрдә хезмәт итү чорларыннан, Россия Федерациясе законнары нигезендә экстремист булып танылган оешмаларда ихтыярый әгъза булып тору чорларыннан, Донецк Халык Республикасына, Луганск Халык Республикасына һәм аларның халкына каршы хокукка каршы гамәлләрдә катнашу чорларыннан, Украина кораллы көчләре һәм

башка формированиеләре составында Россия Федерациясенә каршы хәрби хәрәкәтләрдә катнашу чорларыннан тыш), шул исәптән;

а) даими (штат) нигездә биләгән депутат вазыйфаларын;

б) дәүләт хезмәткәрләре чиннары (ранглары) бирелгән вазыйфаларны;

в) судьялар вазыйфаларын;

г) дипломатик ранглар бирелгән вазыйфаларны;

д) прокуратура хезмәткәрләренең класслы чиннары бирелгән вазыйфаларны;

е) хәрби званиеләр һәм махсус званиеләр бирелгән вазыйфаларны;

ж) чиннар (ранглар) бирелгән җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларны;

з) Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы дәүләт вазыйфаларын;

и) Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе хәрби-граждан администрацияләре вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү максатларында кертелгән шушы органнардагы вазыйфаларны;

к) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә Украина законнары нигезендә эшләгән гавами хакимият органнары вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү максатларында кертелгән шушы органнардагы башка вазыйфаларны.»;

6) 34 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында «конкурс нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 38 статьяның 1 өлешендә «дәүләт хезмәткәрләреннән (гражданнардан)» сүзләрен «дәүләт хезмәткәрләреннән, гражданнардан» сүзләренә алмаштырырга;

8) 39 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) персональ белешмәләр өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, граждан хезмәткәренең бары тик автоматлаштырылган эшкәртү нәтиҗәсендә алынган персональ белешмәләре нигезендә граждан хезмәткәренә карата юридик нәтиҗәләр барлыкка китерә яисә аның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә башка рәвештә кагыла торган карарлар кабул итү тыела;»;

9) 41 статьяның 1 өлешендә:

а) 9 пунктта «дәүләт хезмәткәрләрен» сүзләреннән соң «, гражданнарны» сүзен өстәргә;

б) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) дәүләт хезмәтенә урнашканда һәм граждан хезмәткәре аны узу чорында граждан тарафыннан бирелә торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

в) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ пункт өстәргә:

«16[1]) дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән билгеләнгән рәвештә файдалана алуны рәсмиләштерү;».

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) әлеге Кодексның 18[2] статьясында каралган анкетада булган белешмәләрдәге аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында, яллаучы вәкиле (эш бирүче) карары белән үзгәргән белешмәләрдән тыш (алга таба – анкетадагы белешмәләр), яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача хәбәр итәргә.»;

2) 15 статьяның 1 өлешендәге 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә урнашканда һәм (яисә) аны узу чорында муниципаль хезмәт вазыйфасындагы чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне бозу аны биләүгә комачау итә торган мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы ялган документлар яисә күрәләтә ялган белешмәләр тапшырса, йә муниципаль хезмәт вазыйфасындагы чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне бозу аны биләүгә комачау итә торган мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәүне дәлилли торган документлар һәм (яисә) белешмәләр тапшырмаса;»;

3) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 18[2] статья өстәргә:

«18[2] статья. **Анкета тапшыру, анкетада булган белешмәләрнең үзгәрүе турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү**

1. Граждан муниципаль хезмәткә урнашканда анкета тапшыра.
2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) анкетада булган белешмәләрдәге аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында язмача хәбәр итә.
3. Анкетаның рәвеше, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләрнең исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.
4. Анкетадагы белешмәләр яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) яисә ул вәкаләт биргән затның карары белән тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне

тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүмат булган гавами хакимият органнарына һәм оешмаларга язмача соратулар, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Тиешле мәгълүмат булган гавами хакимият органнары һәм оешмалар соратыла торган мәгълүматны әлеге соратуны алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

4) 19 статьяда:

а) 3 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге Кодексның $18^2$ статьясында каралган анкетаны;»;

б) 4 өлештә «белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

5) 29 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $11^1$ һәм $11^2$ пунктлар өстәргә:

«$11^1$) 2014 елның 11 маеннан 2022 елның 23 февраленә кадәр Россия Федерациясе гражданлыгы алган һәм шушы чорда, даими яшәү срогына бәйсез рәвештә, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территориясендә даими яшәгән Россия Федерациясе гражданнары һәм элек Украина гражданлыгында булган һәм 2022 елның 24 февраленнән башлап Россия Федерациясе гражданлыгы алган Россия Федерациясе гражданнары 1992 елның 1 гыйнварыннан 1993 елның 31 декабренә кадәр Украина ССР Конституциясе, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә гамәлдә булган норматив хокукый актлар нигезендә төзелгән дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында биләгән җитәкчеләр, белгечләр вазыйфаларында, шулай ук даими (штат) нигездә биләгән сайлаулы вазыйфаларда;

$11^2$) әлеге өлешнең $11^1$ пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнары Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә Украина законнары нигезендә 1994 елның 1 гыйнварыннан алып дәүләт вазыйфаларын яисә муниципаль вазыйфаларны биләү, Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә яисә Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә урнашу көненә кадәр биләгән вазыйфаларда (Россия Федерациясе законнары нигезендә террорчы булып танылган хәрби формированиеләрдә һәм башка формированиеләрдә хезмәт итү чорларыннан, Россия Федерациясе законнары нигезендә экстремист булып танылган оешмаларда ихтыярый әгъза булып тору чорларыннан, Донецк Халык Республикасына, Луганск Халык Республикасына һәм аларның халкына каршы хокукка каршы гамәлләрдә катнашу чорларыннан, Украина кораллы көчләре һәм башка формированиеләре составында Россия Федерациясенә каршы хәрби хәрәкәтләрдә катнашу чорларыннан тыш), шул исәптән;

а) даими (штат) нигездә биләгән депутат вазыйфаларында;

б) дәүләт хезмәткәрләре чиннары (ранглары) бирелгән вазыйфаларда;

в) судьялар вазыйфаларында;

г) дипломатик ранглар бирелгән вазыйфаларда;

д) прокуратура хезмәткәрләренең классны чиннары бирелгән вазыйфаларда;

е) хәрби званиеләр һәм махсус званиеләр бирелгән вазыйфаларда;

ж) чиннар (ранглар) бирелгән җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларда;

з) Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы дәүләт вазыйфаларында;

и) Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе хәрби-граждан администрацияләре вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү максатларында кертелгән шушы органнардагы вазыйфаларда;

к) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә Украина законнары нигезендә эшләгән гавами хакимият органнары вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү максатларында кертелгән шушы органнардагы башка вазыйфаларда.»;

6) 34 статьяда:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә урнашканда һәм муниципаль хезмәткәр аны узу чорында граждан тарафыннан бирелә торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

«$11^1$) дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән билгеләнгән рәвештә файдалана алуны рәсмиләштерү;».

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда аларның үз көченә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 3, 8 пунктлары, 9 пунктының «б» һәм «в» пунктчалары һәм 2 статьясындагы 1 – 4 һәм 6 пунктлары 2024 елның 12 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законга һәм «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 605-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 639-ФЗ номерлы федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә әзерләнде.

Закон проектының максаты Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законын күрсәтелгән федераль законнарга туры китерүдән гыйбарәт.

Закон проекты белән дәүләт хезмәтенә яисә муниципаль хезмәткә урнашканда гражданнар тарафыннан бирелүче анкетаның (алга таба – анкета) бердәм рәвешен билгеләү каралган. Анкетаның рәвеше, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләрнең исемлеге, шулай ук аларны актуальләштерү тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Президенты акты белән билгеләнәчәк.

Закон проектында дәүләт хезмәткәрләренә һәм муниципаль хезмәткәрләргә анкетада булган белешмәләрнең үзләренә мәгълүм булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә язма рәвештә хәбәр итү бурычы билгеләнә.

Шул ук вакытта яллаучы вәкиленең яисә ул вәкаләт биргән затның карары белән әлеге белешмәләрне тикшерүне үткәрү мөмкинлеген билгеләү тәкъдим ителә. Мондый тикшерүне үткәрү дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә йөкләнә, алар гавами хакимият органнарына һәм тиешле мәгълүматка ия оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша да, соратулар җибәрәчәк. Күрсәтелгән органнар һәм оешмалар соратылган мәгълүматны мондый гарызнамә алынган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

Закон проектында шулай ук дәүләт хезмәткәрләре булган гражданнарның, алар тарафыннан Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм итү турындагы контрактлар төзелгән очракта, алар биләгән дәүләт хезмәте вазыйфаларын саклап калуның хокукый гарантияләре дә беркетелә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанс чараларын бүлеп бирүне таләп итми.